Алга, белем иленә!

# Мәктәбем минем

Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче лицей
«Фарватер» укучыларының нәфис басмасы

24 нче октябрь, 2016 нчы ел


**Әлеге санда:**



**Исәнме, көз!(1 нче бит)**



**Тарих сәхифәләре (2 нче бит )**



**Илһам канатында (3 нче бит)**



**Мәктәп хәбәрләре (4 нче бит )**

### «Көз көннәре»

Көз көннәре килеп житте,
Хушлашабыз җәй белән.
Бөтен җиргә яфраклардан
Алтын келәм җәелгән.
Көз көннәре бик күңелле,
Бик күп җимешләр пешә.
Помидор, карбыз өлгерә,
Алмалар өзелеп төшә.
Көз җиттеме, җир өстенә
Алтын яфрак җәелә.
Карап туеп булмый һич
Бу фасылның яменә.

### «Көз»

Киң болыннарда,
Урман-кырларда,
Агачлар, гөлләр
Кибеп сулдылар.
Уйсу җирләрдә,
Елга, күлләрдә,
Көзге салкыннан
Сулар туңдылар.
Көннәр суынды,
Чишмәләр тынды,
Безне калдырып
Кошлар да китте.

**Мөхәррирләр**



Табигать һәрвакыт үзгәреп тора. Ел фасыллары алмашынган саен табигать тә яңа киемнәрен кия. Менә хәзерге вакытта да, узенең алтын яфраклары белән, көз килеп житте. Бу ел фасылы, башкаларыннан аеруча матур, урманнар, болыннар үзләренә генә хас бер төскә керәләр. Каеннар иң беренче булып яфракларын коя башлыйлар, ә инде аннан соң калган агачлар да, киемнәрен алыштыралар.Алтынсу төсләр һәрвакыт күңелләрне генә күтәреп тора. Дөнья шундый төсләргә күмелгән чакта, елмаймыйча булмый.

**Асилә Валеева, 4 нче В сыйныфы укучысы**

**Күренекле татар язучысы, драматург Мәхмүт Галәүнең тууына 130 ел!**

XX йөз татар реалистик прозасының күренекле вәкиле, татар әдәбиятында тарихи роман жанрына нигез салучыларның берсе, драматург, журналист, нашир, публицист, тәрҗемәче Мәхмүт Галәү (Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани) 1886 нчы елның 8 нче сентябрендә Казан губернасының Арча өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Арча районы) Ташкичү авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә.

Тумышы һәм нәсел шәҗәрәсе белән ул татарның бөек мәгърифәтчесе, дин һәм тарих галиме Шиһабетдин Мәрҗанигә якын кардәш туры килә. Әдипнең бабасы – Ш.Мәрҗанинең бертуган энесе. Большевиклар инкыйлабына кадәр Мәхмүт Галәү үзе дә, әдип һәм журналист буларак, язган әсәрләрен «Мәрҗани» имзасы белән бастыра. 1897-1903 нче



елларда Казанда мәдрәсәдә укый. 1903-1907 нче елларда Әстерхан шәһәрендә укытучы булып эшли. «Туп» журналын оештыручыларның берсе һәм мөхәррире була.

Актив иҗат чоры 1920 нче елларга туры килә. Яңаның иске белән көрәше, авыл-шәһәр мөнәсәбәтләре, яңа кеше тәрбияләү темаларына багышланган очерклары һәм хикәяләре белән матбугатта еш чыгышлар ясый.

1920 нче елларга хас булган яңа кыйммәтләрне мактау, искелек билгеләрен инкарь итү күренешләре «Каяу» (1927), «Төеннәр» (1928), «Күпнең берсе» (1931) исемле җыентыкларга кергән хикәяләрендә чагылыш таба.

Мәхмүт Галәү үзен драматургиядә дә сынап карый: «Саламторханнар» (1926), «Пугач явы» (1926) пьесаларын яза.

«Болганчык еллар» («Ил тыныч чакта»), «Мөһаҗирләр» («Ил өреккәндә») романнары бүгенге көндә татар әдәбияты хәзинәсенең иң күркәм, иң мөһим казанышларыннан саналалар. Бу әсәрләр Мәскәүдә 1930 нчы һәм 1934 нче елларда, рус теленә тәрҗемә ителәләр.

**Эмиль Инсафетдинов, 8 нче ЕМ сыйныфы укучысы**





## «Көзге матурлык»

Әле кичә генә җәйне көтеп алган идек. Матур, кызу, күңелле көннәре белән җәйнең үтеп киткәнен сизми дә калдык. Ә бүген инде көз! Бакчадагы тулып пешкән җимешләре, кырдагы мул уңышлы игеннәре белән кешеләрне сөендереп, җиргә алтын көз аяк басты. Минемчә, көзне сары төсе өчен генә түгел, ә көзге байлык, муллык өчен дә алтын көз дип атыйлар. Урманда да көзге уңыш бик күп була. Гөмбә, чикләвек, балан, алма, миләшне кышка җитәрлек итеп җыярга була. Табигать үзенчә матурая башлый. Тирә-яктагы яшеллек, күзгә күренеп, төсен сарыга үзгәртә. Көз көне җәйге яллар тәмамланса да, мин көзне яратам. Чөнки көз җиткәч, без җәй буена күрмәгән сыйныфташлар белән очрашабыз.

**Гарипова Зилә, 3 нче В сыйныфы укучысы**





**Гаязова Азалия, 3 нче Б сыйныфы укучысы**

## «Көз килде»

Туган ягыма
Алтын көз килде.
Барлык агачлар
Алтынсу күлмәк киде.

**Миндубаева Альбина, 4 нче В сыйныфы укучысы**



**Гарипов Наил, 3 нче Б сыйныфы укучысы**

# Мәктәп хәбәрләре

## 1 нче сентябрь – Белем бәйрәме!

Менә кояшлы 1 сентябрь таңы безне кабат бергә җыйды. Бу көнне һәрберебез дулкынланып, шатланып каршы ала: беренче тапкыр мәктәпкә баручы да, өлкән сыйныфларда укучы да, әти-әниләр дә. Бүген мәктәпләрдә һәр бала көтеп алган кызыклы вакыйгаларга бай булган яңа уку елы башлана. Күңелләрдә сөенеч, йөзләрдә шатлыклы елмаю балкый. Яңа уку елы һәркемгә шатлык-сөенечләр, бары “4”ле һәм “5”леләр генә алып килсен. Бәйрәм белән сезне, дуслар!

**Мөхәррирләр**









## *“Яхшылык дәресе”*

5 нче сентябрь көнне лицеебызда, “Яхшылык дәресе” уңаеннан, биатлончы һәм чаңгычы Полякова Ирина Васильевна белән очрашу булды. Кышкы Паралимпиа уеннарының көмеш призёры һәм чемпионы, күп тапкырлар дөнья чемпионы укучыларга үзе турында, үзенең спортта ирешкән казанышлары хакында сөйләде. Бу очрашу безгә бик ошады.

**Петров Эмиль, 4 нче Г сыйныфы укучысы**






“Минем көндәлек режимым”

Мин иртән сәгать алтыда йокыдан торам, зарядка ясыйм, юынам, иртәнге ашны ашыйм. Аннан соң киенәм һәм мәктәпкә китәм. Мәктәптә мин укыйм, язам, мәсьәлә, мисал чишәм. Дәресләр сәгать бердә бетә. Аннары мин көндезге ашны ашыйм. Сәгать икедә мин өйгә кайтам. Өйдә мин әнигә булышам һәм ял итәм, ә аннан соң дәресләр әзерлим.Сәгать алтыда кичке ашны ашыйм. Сәгать тугызда йокларга ятам.

**Гарипова Зилә, 3 нче В сыйныфы укучысы**

**Зәлидә Әхмәтова, 3 нче В сыйныфы укучычы**







**Бикмуллина Сәмирә, 3 нче В сыйныфы укучысы**

# Мәктәп хәбәрләре

## “Субботник”





Табигать ул – безнең әйләнә–тирәбез. Табигать матурлыгы – ул безнең матурлык. Кызганычка каршы, бүгенге кешелек табигатьнең кадерен белеп бетерми. Табигатебезнең чиста сулы елга – күлләрен пычрату, очсыз – кырыйсыз урманнарын бер мәгънәсез кисеп бетерү, химия заводларның агулы газлары белән чиста һавабызны бозу, урамнардагы чүп–чарларның җәелеп ятуы күңелләрне тетрәндерә. Моны булдырмау – ул безнең изге бурычыбыз. Шул максаттан 8 нче октябрь көнне лицеебызда субботник оештырылды. Барлык сыйныфлар да үзләренә бүленеп биргән территорияне тәртипкә китерде. Әйләнә-тирә матурланып, чистарып калды.

**Алсу Ахмадуллина, 9 нчы Г сыйныфы укучысы**

## “Күрү көне”

13 нче октябрь — “Күрү көне” уңаеннан, югары сыйныф укучылары башлангыч сыйныфта укучы балаларга күзләр өчен гимнастика ясаттылар. Укучылар күзләргә төрле күнегүләрне теләп эшләделәр. Мондый чаралар аларга бик ошады.

**Галиев Рүзәл , 5 нче М**



**сыйныфы укучысы**

## “Финанс грамотлылык”

7 нче сентябрь көнне 9,10,11 нче сыйныф укучылары өчен “Финанс грамотлылык” дәресе үткәрелде. Әлеге дәресне “Россия” банкы вәкиле Шверко Владислав Александр улы алып барды. Укучылар аңа үзләрен кызыксындырган сорауларны бирделәр һәм барысына җавап алдылар.

**Мөхәррирләр**



# Илһам канатында

**“Курчагым”**

Әнием мине ярата,
Иркәли, сөя.
“Мин бит сине бик яратам”,
“Сабыем”,-дия.
Мин дә кулыма курчак алып,
Әни булып уйнадым.
Күкрәгемә кысып кочып,
Башкаеннан сыйпадым.

**Гильметдинова Лилия,**
**2 нче Г сыйныфы укучысы**






**Галиуллин Раил, 4 нче В сыйныфы укучысы**

**Минем яраткан йорт хайваннарым: этем һәм песием.**

**Лапшина Ульяна, 4 нче В**




**сыйныфы укучысы**

## “5 нче октябрь — Укытучылар көне”

5 нче октябрь көнне бар Россия Укытучылар көнен бәйрәм итте. Әле мәктәптә укучылар да, инде күптән белем йортын тәмамлап, хезмәт куючылар да – барысы да мөгаллимнәрне әлеге һөнәри бәйрәмнәре белән тәбрикләде. Безнең лицеебыз укучылары да бәйрәм уңаеннан бик матур концерт программасы әзерләде. Барысына да бәйрәм концерты ошады.

**Хәйруллин Алмаз, 5 нче К сыйныфы укучысы**





## “Киләчәккә билет”

2016 нчы елның 10 нчы октябрендә “Киләчәккә билет” республика конкурсының муниципаль иҗади эшләр этабында 8 нче сыйныф укучысы Инсафетдинов Эмиль үзе язган шигыре белән катнашып, I урынга лаек булды. 8 нче сыйныф укучысы Алепкерова Талия бу номинациядә II урынны яулады. 9 нчы сыйныф укучысы Садреева Ильвина инша номинациясендә катнашып, I урынга лаек булды. Әлеге номинациядә 7 нче сыйныф укучылары Леонтьева Әдилә II урынны, Вильданова Алинә III урынны яулады. 9 нчы сыйныф укучысы Таксеитова Алия шулай ук III урынга лаек булды. Инсафетдинов Эмиль, Садреева Ильвина, Таксеитова Алия республика турына үттеләр. Аларга уңышлар телибез.

**Инсафетдинов Эмиль, 8 нче ЕМ сыйныфы укучысы**

# Илһам канатында

“Йөрәк табибы булам”

Йөрәк табибы булам мин,
Әллә йөрәк янганга,
Әллә синең йөрәгеңә
Зур яралар салганга?!
Йөрәк табибы булам мин,
Әллә хыял булганга,
Синең белән киләчәктә
Үз юлымны ялгарга...
Йөрәк табибы булам мин...
Табиб булам. Алдатмам!

**Садреева Ильвина, 9 нчы А сыйныфы укучысы**



## “Табиб булам”

Балачактан бирле булган хыялым – табиб булу. Әле дә исемдә: башка балалар курчак, матур сумка сораганда, мин әнидән гел стетоскоп сорый идем. Туган көнемдә алган иң зур бүләк тә шул булды.

Бүген исә, мин төгәл беләм: киләчәктә Лео Бокерия, Вернер Юнг кебек танылган табиб-кардиолог булачакмын. Кеше организмындагы иң хисле һәм шул ук вакытта иң мөһим, гаҗәеп әгъза белән эш итү минем өчен зур хыял булып кала. Кешенең хис -кичерешләрен, тормышындагы барлык вакыйгаларын үзе аша үткәргән йөрәкне дәвалау һәм кешегә яшәргә мөмкинлек бирү – минем иң зур хыялым.

**Садреева Ильвина, 9 нчы А сыйныфы укучысы**

# Тәбрикләү сүзләре!

“Укытучыма”

Рәхмәт сезгә,укытучым,
Сез безне яраттыгыз.
Сабыр гына барыбызга
Күп белем тараттыгыз.
Рәхмәт сезгә,укытучым,
Сезне тыңлап үстек без.
Үз юлыбызны табарга
Өйрәттегез безне сез.
Рәхмәт сезгә,укытучым,
Сезгә саулык телибез.
Сезнең барлык өметләрне
Без акларга уйлыйбыз.

**Гарипов Наил, 3 нче Б сыйныфы укучысы**






“78 нче лицей “Фарватер” укучылары укытучыларны **һөнәри бәйрәмнәре—”Укытучылар көне”**белән котлый. Хөрмәтле Укытучыларыбыз! Сезне һөнәри бәйрәмегез белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Авыр, әмма җаваплы һәм мактаулы эшегездә зур уңышлар, саулык-сәламәтлек, бәхет, шатлык, озын гомер телибез. Безнең илдә кеше бәяләп бетерә алмаслык кыйммәтле хәзинә. Кешеләр илнең хуҗасы һәм терәге. Ә илебез киләчәгенең терәге сезнең кулларда, хөрмәтле укытучыларыбыз! Сез кешеләргә белем ачкычы бирәсез, кешеләрне кеше итәсез,олы юлга илтәсез.Сезгә барысы өчен олы рәхмәтебезне белдерәбез.

**Мөхәррирләр:** А.Валеева, Э.Петров, А.Әхмадуллина, Э.Инсафетдинов.

**Консультант:** Г.М.Нәбиева

Безнең адресыбыз: Казан шәһәре Идел буе районы “78 нче лицей “Фарватер”
(Ю.Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139
тел./ факс 268-58-61.
E-mail: school_7878@mail.ru
S78kzn@edu.tatar.ru

Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин: https://edu.tatar. ru/priv/ school78.htm/page813169. htm

Хатларыгызны түбәндәге адреска юллагыз:
gulchachak.gumerova@yandex.ru